Барлык илләрнең пролетарийлары, берләшегез!

# Татарстан КОММУНИСТЫ

№5-6 (17-18). 2011 ел, 25 май. КПРФның Татарстан региональ бүлеге иҗтимагый-политик газетасы




*Россия, хезмәт, халык власте, социализм!*
**РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ КОММУНИСТЛАР ПАРТИЯСЕ**




## Халык референдумы колач җәя

Әйе

Әйе

**КПРФ Үзәк Комитеты игълан иткән «Халык референдумы» үзенең беренче яртысын уңышлы тәстә узды. Бу турыда партия оешмаларыннан куанычлы хәбәрләр килә. Узган 4 ай эчендә Татарстан буенча 50 меңнән артык тавыш җыелды.**

Үз хезмәте белән яшәүчеләр бүген яклауга мохтаҗ. Аларның законлы интереслары өчен бүгенге Россиядә бай олигархлар режимы берни дә эшләмәячәк. Халыкның гражданлык ирегең буарга һәм социаль хокукларын аяк астына салып таптарга властьларга ирек бирмәү өчен Коммунистлар партиясе көченнән килгәннең барын да эшли. Массовый протест акцияләрендә һәм парламент трибуналарында ил илнең социаль-экономик һәм политик курсын кискен үзгәртүне таләп иткән чыгышлар коммунистлар тарафыннан көннән-көн көчләрәк ишетелә.

КПРФ членнары һәм тарафдарлары 1 февральдән 30 сентябрьгә кадәр «Халык референдумы» эшендә катнаша. Сезнең һәркайсыгыз әлеге активистлардан бюллетень алып, анда куелган сорауларга «Әйе», яки «Юк» дип җавап бирә ала.

Бюллетеньнәр берләштерелеп, Дәүләт Думасы сайлаулары алдыннан ил җитәкчелегенә җиткереләчәк һәм партия матбугаты битләрендә игълан ителәчәк. Властьлар үткәрә торган политиканың халык һәм ил файдасына булуын таләп итү безнең барыбызның да бурычы.



**Рамил ГАЙФУЛЛОВ,**
**КПРФның Татарстан Республика Комитеты секретаре.**

## Татарстан депутаты А. Прокофьев Россия Президенты белән очрашты һәм Грециядә булды

**13 майда Кострома шәһәрендә Россия Президенты Д.А. Медведев парламент партияләренең яшь депутатлары белән очрашты. Анда Татарстан вәкиле – Дәүләт Советының КПРФ фракциясе депутаты Артём Прокофьев катнашты.**

Очрашуда илдәге социаль һәм экономик үзгәрешләр, коррупциягә каршы көрәшне көчәйтү һәм Россия политик системасының киләчәге мәсьәләләре каралды. Киләчәк хакына, хәзерге политик системаның иң яхшылардан булмавын искә алып, аны яхшырту кирәк, диде Президент. Дәүләт башлыгы сайлау процессын техник модернизацияләү зарурлыгын да билгеләп үтте. Политик һәм административ системаны «яшәртү» зарурлыгы ассызыкланды.

Мондый очрашулар дәими төс алды. Депутат А. Прокофьевның аларда инде җиденче тапкыр катнашуы.



*ГКП Үзәк Комитетында төшкән фото*

**Греция башкаласы Афина шәһәрендә 27-28 апрель көннәрендә, традицион туганлык мөнәсәбәтләре кысаларында, КПРФ вәкилләренең Греция Коммунистлар партиясе (ГКП) җитәкчеләре һәм грек парламенты депутатлары белән очрашулары булды.**

Аларда безнең яктан КПРФ Үзәк Комитетының информацион-аналитик эш һәм сайлау кампанияләрен үткәрү бүлеге мөдире урынбасары, Татарстан Дәүләт Советы депутаты, политик фәннәр кандидаты Артём Прокофьев (рәсемдә уңнан икенче) һәм КПРФ Үзәк Комитетының халыкара бүлек мөдире Андрей Филипповлар катнашты. Греция ягыннан ГКП Үзәк Комитеты Политбюросы членнары Георгиос Маринас, Димитриос Гондикас һ.б.лар булды.

Алдан килешенгәнчә, сайлау кампанияләрен үткәрү тәҗрибәсе белән уртаклашу үткәрелде. Коммунистлар яклавы белән сайланган депутатлар һәм муниципаль җитәкчеләр белән үзара хезмәттәшлек аша җәмгыятьтә коммунистларның йогынтысын киңәйтү буенча тәҗрибәсе тикшерелде. Очрашуда катнашучылар ике ил партияләренең халыкара чараларда катнашу мәсьәләләренә дә кагылып үттеләр.

**КПРФ Үзәк Комитетының матбугат хезмәте.**

## *Министр да безнеңчә уйлый*

Илнең юстиция министры Александр Коновалов россиялеларнең ни өчен законга ышанмавын аңлаткан. Аның әйтүенчә, бүген илдә кабул ителүче законнар артык озын, бер-берсенә каршы килә һәм аларның системасы юк. «Закон кабул иткәндә гражданнар фикере дә исәпкә алынмый», – дигән ул. Министр бу өлкәдә тәртип урнаштырырга киңәш иткән.



## Социалистик Хезмәт Герое Алмас Булатовка 80 яшь

Татарстан Дәүләт Советының КПРФ фракциясе, партиянең Татарстан республика комитеты, «Татарстан коммунисты» газетасы һәм республикабыз коммунистлары данлыклы милләттәшебез Алмас Харисович Булатовны юбилее белән кайнар котлыйлар, аңа ныклы сәламәтлек, бәхетле озын гомер телиләр.

Юбиляр бүгенге көндә балалары ярдәмен тоеп, җәмәгате Мәйсәрә ханым белән Азнакай районы Зур Сукаеш авылында яши. Ул бөтен гомерен авыл хуҗалыгына багышлаган легендар шәхес. Татарстанның бик күп игенчеләре аның үрнәгендә тәрбияләнде. «Җир мине кеше итте, җиргә булган мәхәббәт миңа иң кадерле һөнәрне бирде, күкрәгемә Алтын Йолдыз кадады»,– ди ул.

Аның күпсанлы орден-медальләре арасында СССРның дәүләт бүләге булган Ленин ордены белән рәттән КПРФ Үзәк Комитетының «Бөтенсоюз Ленинчыл Коммунистик Яшьләр Союзына 90 ел» истәлек медале дә бар. Узган гасырның 80нче елларыннан ул КПСС яшьүдән туктаганга кадәр Азнакай районы «Тырыш» колхозының башлангыч партия оешмасы секретаре булды. Алмас Булатовның яшь буынга үрнәк тормышы, аларны үз Ватаннарының патриотлары итеп тәрбияләүдәге хезмәтләре бәяләп бетергесез.

Геройның әтисе белән бертуган Фатыйх Булатов та Бөек Ватан сугышында генерал-майор дәрәҗәсенә күтәрелеп, милләтебез горурлыгына әйләнде.

***Рәсемдә Алмас Булатов Татарстан АССР Верховный Советы президиумының 1980 еллардагы председателе Әнвәр Баһаветдинов белән.***

## «Правда» газетасына язылыйк!

2012 елның 5 маенда В.И. Ленин инициативасы белән чыга башлаган «Правда» газетасына 100 ел тула. Коммунистлар партиясе идеяләрен халыкка җиткерүче иң абруйлы газета ул. Аны чит илләрдә дә алалар, Россиядәге чынбарлыкны шушы газета аша ачыкларга тырышалар. Хәзерге тормышның иң дөрес яктыртучы, хезмәт кешесе турында кайгыртып хак сүзне дәлилләп аңлатучы басма буларак аңа тиңнәр юк. Газета битләрендә галимнәр, космонавтлар, депутатлар, сугыш һәм хезмәт ветераннары, культура эшлеклеләре һәм әлбәттә, партия җитәкчеләре илебезне саклап калу буенча эшлекле чыгышлар ясыйлар. Татарстаннан хәбәрләр даими басылып килә. Республикабыздагы тискәре күренешләр кискен тәнкыйть утына тотыла. «Правда» газетасы алда торган Госдума һәм Президент сайлаулары алдыннан безгә дөрес юл күрсәтүче маяк булып тора. Газетаның һәр санын интернет аша www.gazeta-pravda.ru сайтыннан да укып барырга була. Газетаны кулга тотып укуны өстенрәк күрүчеләр аңа почта бүлекләренә барып языла алалар. Әшне җиңеләйтү максатыннан подписка бланкасын газетабыз битенә урнаштырабыз. Аны кисеп алып, теләсә кайсы айдан газетага языла аласыз. Ярты елга язылу бәясе – 607 сум 80 тиен.

Ф.СП - 1

АБОНЕМЕНТ на газету
**ПРАВДА**

**50102**

**На 2011 год по месяцам**

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда
(почтовый индекс) (адрес)
д. корп. кв.
Кому
(фамилия, инициалы)

| ПВ | место | литер |
|---|---|---|

**ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА**
на газету **50102**
(индекс издания)

**ПРАВДА**

| Стоимость | подписки | | Количество комплектов: | |
|---|---|---|---|---|
| | переадресовки | руб. | | |

**На 2011 год по месяцам**

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда
(почтовый индекс) (адрес)
Кому
(фамилия, инициалы)

**Бәйрәм кайтавазы**




**Ничәмә-ничә тапкыр инандык инде: «единоросслар» өчен «закон язылмаган». Россия Федерациясендә Законнар бары тик оппозицион партия вәкилләре һәм гади гражданнар тарафыннан гына үтәлергә тиеш булып чыга. «Единороссллар» үзләре исә ул законнарны үтәргә җыенмыйлар да. Ә нигә? Аны бит алар үзләре уйлап чыгара.**

Узган 2010 елда, 8 июль көнне, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унберенче утырышында дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, КПРФ фракциясе члены Рафаил Фәттах улы НУРЕТДИНОВ түбәндәге эчтәлектәге политик белдерү белән чыккан иде. Менә аннан бер өзек:

*«Хөрмәтле Президиум, хөрмәтле депутатлар, чакырылган затлар!*

*2010 елның 7 маенда мин Чаллы шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе В.Г. Шәйхразыев әфәндегә Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 65 еллыгына багышлап уздырыла торган шәһәр бәйрәмендә миңа да сүз бирүләрен сорап мөрәҗәгать иттем һәм әлеге мәсьәлә буенча нинди карар кабул ителүе турында миңа алданрак хәбәр бирүләрен үтендем. Мондый соравым шәһәребез халкының коммунист-депутатның да котлавын ишетәселәре килү турындагы күп санлы үтенечләрен канәгатьләндерү максатыннан бирелгән иде.*

*9 май көнне, бәйрәм башланыр алдыннан, башкарма комитет вәкиле сүзләреннән миңа да котлау өчен сүз бирәчәкләре аңлашылды. Әмма трибуна каршында ФСБ полковнигы (ул үзен шулай дип таныштырды, дөрес, документларын күрсәтмәде) мине туктатып, сорау бирде: «Сез нәрсә, чыгыш ясарга җыенасызмы?». Миннән уңай җавап ишеткәч, берни аңлатып тормастан, кара киемдәге берничә таза егет трибунага бару юлыма аркылы бастылар, ә полковник яңашәдә торды.*

*Билгеле, коммунист-депутатка сүз бирүче булмады.*

*12 май көнне минем мөрәҗәгатькә җәмәгатьчелек белән элемтә бүлеге начальнигы кул куйган җавап килде, анда техник сәбәпләр аркасында минем үтенечне канәгатьләндерә алмаулары турында әйтелгән иде...».*

Коммунист-депутат Р.Ф. Нуретдинов чыгышыннан соң ТР Дәүләт Советы председателе Ф.Х. Мөхәммәтшин бу хәл буенча барысына да ачыклык кертергә ышандырды.

Һәм ул «ачыклады»... Нәтиҗәдә: 2011 елның 18 апрелендә коммунист-депутат Нуретдинов, Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 66 еллыгына багышланган гомумшәһәр митингында үзенә сүз бирүләрен сорап, бу юлы инде шәһәр мэры Васыйл Гаяз улы Шәйхразыевка тагын мөрәҗәгать итте. Бәйрәм җитәргә берничә көн вакыт калгач, Р.Ф. Нуретдиновның ярдәмчеләре ни өчен һаман җавап юклыгы турында белешергә тырышып карыйлар. Чаллы шәһәре хакимияте вәкилләре белән телефоннан сөйләшүләр вакытында депутат ярдәмчеләренә коммунист-депутатка чыгыш ясау өчен беркем дә сүз бирергә җыенмавын, мондый карарның республика җитәкчеләре тарафыннан кабул ителүе турында ачык аңларга мөмкинлек бирделәр.

Р.Ф. Нуретдинов Татарстан Республикасы Дәүләт Советы председателе Ф.Х. Мөхәммәтшинга шалтыратырга тырышып карый, әмма аның урынбасары Р.А. Ратникова белән генә сөйләшергә насыйп була, ул да, узган ел Фәрит Хәйруллович ышандырганча, барысын да ачыкларга сүз бирә.

**Мәгълүмат өчен белешмә:**

2004 елның 26 февралендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» №15-ЗРТ Татарстан Республикасы Законы, ә 2010 елның 9 июнендә «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турындагы Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» № 38-ЗРТ Законы кабул ителә.

**14.1 статья. Депутат мөрәҗәгате.**

Дәүләт власте, җирле үзидарә органнарына, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләргә кергән депутат мөрәҗәгатьләре, компетенцияләренә туры килә торган җитәкче затлар тарафыннан мөрәҗәгать теркәлгәннән алып җиде көн эчендә каралалар, күрсәтелгән сроктан да соңга калмыйча, депутатка сораган мәгълүматларны, яисә белешмәләр бирелә...

**30 статья. Депутат эшчәнлеген алып баруга каршылык тудырган өчен җаваплылык.**

Татарстан Республикасы Дәүләт власте органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләрнең җитәкче затлары әлеге Закон положениеләрен үтәмәгән, шул исәптән депутат запросларына һәм мөрәҗәгатьләренә мәгълүматлар һәм җаваплар бирү срокларын һәм тәртибен бозган, белә торып ялган мәгълүмат биргән, мәгълүмат бирүдән хаксызга баш тарткан, аны бирүдән читләшкән, депутатларны кабул итү тәртипләрен бозган өчен Законда каралган тәртиптә җавап тоталар.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Рафаил Фәттахович Нуретдинов шәһәр мэрыннан җавапны көтеп тә ала алмый.

Безнең илдә менә шундый демократия, законнар шулай үтәлә. Власть «Сүз (закон) минеке, теләсәм – бирәм, теләсәм – кире алам» принцибы буенча яши.

«Единороссллар» нәрсәдән куркыккан соң?

**Татарстан Дәүләт Советы депутаты Р.Ф. Нуретдинов:**

# Россиядә законнар кемнәр өчен языла?




## Депутат Р. Нуретдиновның митингта ясарга тиешле чыгышының тексты

**Кадерле иптәшләр!**

Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 66 еллыгы уңаеннан ихлас котлауларымны кабул итегез!

Без киләчәк буыннар хакына үз гомерләре бәрабәренә азатлык һәм бәйсезлек яулап алган әтиләребезнең, бабаларыбызның сугыштагы һәм хезмәттәге батырлыклары белән горурланабыз! Без дәһшәтле сугыш елларында барысына да түзгән, авырлыкларны җиңеп чыккан, җимерелеп беткән җәрәхәтле илебезне торгызган халкыбызның чыдамлыгы, рухи ныклыгы белән горурланабыз!

Сугыш – күп гомерләрне кыйган канлы сугыш – дәүләтләрнең һәм капма-каршы идеологияләрнең үзара чәкәләшүе генә түгел, ә җирдәге цивилизациянең киләчәге өчен хәлиткеч бәрелеш иде.

Бу бөек каршылыкта Советлар Союзы хәрби һәм экономик яктан гына түгел, ә идея-политик һәм мораль яктан да җиңү яулады.

Сугыш барлык совет кешеләренең моңа кадәр тарихта күрелмәгән фидакарьлек үрнәкләрен ачып бирде. 11 575 сугышчыга Советлар Союзы Герое исеме бирелү массовый геройлык турында сөйли. Аларның 70 проценттан артыгы – коммунистлар. Коммунистларның фронтта ия булган бердәнбер өстенлеге – һөҗүмгә беренче булып күтәрелү, башкаларны да үз артыннан ияртү иде.

Шунысын да әйтү кирәк, соңгы елларда күмәк мәгълүмат чаралары гади солдатның да, күренекле маршалларның да каһарманлыкларын киң яктырта. Әмма, бер исем һаман да кара пәрдә артында кала бирә: ата-бабаларыбыз үлемгә каршы ташланганда: «Ватан өчен! Сталин өчен!» – дип күтәрелгәннәр. Советлар Союзы Коралы Көчләре Башкомандующие Генералиссимус Сталин – Бөек Җиңүгә рухландырган һәм шуны оештырган төп көч булган ләбаса!

Рәсми пропаганданың Җиңү Коммунистлар партиясенә һәм Сталинга үч итеп яуланган дип расларга тырышуы – оятсызларча ялган ул!

Уинстон Черчилль 1959 елда болай дигән: «Авыр сынау елларында Россия белән даһи һәм какшамас полководец Сталинның җитәкчелек итүе Россия өчен бәхет иде. Ул – үзе яшәгән искиткеч кырыс чорның рәхимсезлекләре вакытында да башкаларны үзенә җәлеп итә алган күренекле шәхес. Сталин искиткеч энергияле, эрудицияле, сыгылмас ихтыяр көченә ия кеше. Ул сукалы Россияне кабул итеп алды һәм атом коралы белән тәэмин итеп калдырды. Юк! Аның турында ни генә сөйләсәләр дә, тарих һәм халык андыйларны онытмый!»

1953 елда Сталин гаять сәер шартларда вафат була. Хәзерге заман тарихчыларының аны Хрущев тарафдарлары агулаганлыгы турындагы версиясе бик тә ышандырыгыч. Аның «шәхес культы» дигән булып фаш итүләрне оештыру бары тик власть өчен көрәшү һәм үз җинаятьләрен яшерү өчен генә кирәк була. Хрущев тарафыннан Сталинга каршы яла ягу кампаниясе җәелдерелү илебезнең халыкара абруена да авыр сукты.

Сталинны «фаш итүнең» көнбатышның махсус службалары кул астында Горбачев белән Яковлев оештырган икенче дулкыны Советлар Союзының таркалуына һәм Россия әле дә булса баш күтәрә алмаган авыр нәтиҗәләргә китерде.

Ә бүген «сталинизмга» каршы көрәшнең өченче дулкыны игълан ителде. Әмма 2011 елның апрель аенда «Суть времени» иҗтимагый хәрәкәте активистлары уздырган россиякүләм сораштыруларның нәтиҗәләреннән күренгәнчә, илебездә яшәүчеләрнең 90 процентка якыны Медведевның «десталинизация» программасына карата кистереп: «Юк!» – дип җавап бирде. Хаклы булган Черчилль, Сталинны беркайчан да онытмаячаклар, чөнки ул үзе өчен дип түгел, ә халык өчен дип яшәгән, халык өчен эшләгән, үзеннән соң хан сарайлары да, чит илләрдә акчалар да калдырмаган. Менә шуңа күрә дә аны Советлар илендә яратканнар һәм үлгәч, ярсып елаганнар. Ә бүгенге көндә халык хәерчелектә яшәвенә зар елый, чөнки ул бүген хакимлек итүче, Россиянең Генералиссимус Сталин исеме белән һәм аның байрагы астында яңаруыннан, социалистик үсеш юлына кайтуыннан котлары очып куркып торучы олигархлар төркеме тарафыннан таланган.

**Кадерле иптәшләр!** Әйдәгез, Бөек Җиңүнең 66 еллыгын һәлак булганнар истәлегенә һәм совет иле тарихын мәсхәрәләүләргә каршы протест колонналарында саф-саф булып, бергә-бергә каршы алыйк! Абыйларыбыз, әтиләребез, бабаларыбыз саклаган, исән калдыру хакына гомерләрен биргән кыйммәтләрне: Совет властен, социализмны һәм Советлар Союзын торгызыйк!

Сезнең алда баш иябез, кадерле ветераннар! Сезгә чын күңелдән ныклы сәламәтлек, күңел көрлеге, тынычлык, иминлек һәм балаларыбызның, оныкларыбызның якты киләчәгенә өмет белән яшәвегезне телим!

Ә Россиянең киләчәге – яңарган социализм! Бәйрәм белән Сезне, кадерле иптәшләр! Бөек Җиңү көне белән!

«Единороссллар»ның Генералиссимус Сталиннан котлары очып тора. Франция президенты Шарль де Голль ничек алдан күрә белгән, ул болай ди: «...Сталин узганнарда калмады. Ул хәзер дә арабызда...».

**Мәктәпләрдә — соңгы звонок**

# Әти-әниләр керем чыганагы...

Мәктәпләрдә авыр ясак рәвешендә акча таләп итү күмәк төс алды. Әти-әниләр балаларын саклау өчен дә, мәктәпне ремонтлау өчен дә, уку әсбаплары, дәреслекләр сатып алу өчен дә, БДИ (ЕГЭ) тапшыру өчен дә, тагын бик күп нәрсәләр өчен түлиләр. Менә бер мисал: 26 март көнне Азнакай районында 9нчы класс укучылары математикадан БДИ биреп карадылар. 500дән артык укучыны район үзәгендәге 6нчы мәктәпкә китерделәр, һәркайсыннан 200әр сум акча түләтеп, имтиханга керттеләр. Шундый ук имтихан рус теленнән дә бар. 11нче класслар өчен ул кыйммәткәрәк төшә – һәрберсе 300 сум түли.

Элек җиңел иде – чирек төгәлләнгәндә һәм уку елы ахырында бар классларда да контроль эшләр эшләнә һәм шул җитә дә иде, бернинди финанс чыгымнары да таләп ителмәде. Барлык мәшәкатьне укучыларның белем дәрәҗәсен тикшерү эше ышанып тапшырылган шул ук мәктәп укытучылары башкара иде. Ә хәзер? Арадашчы фирма укучылардан акча җыюны оештыра, әйтерсең алар машина йөртү таныклыгы шикелле бер документ ала.

Акча җыючылар үз гамәлләрен түләүле мәгариф хезмәтләре күрсәтү турындагы килешүләргә сылтап нигезлиләр. 26 мартта шундый килешү Казан шәһәрендәге «Центр» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры Марина Бикбаева белән Азнакайдагы әти-әниләр арасында да төзелә. Әти-әниләр – заказчы, ә фирма – эш башкаручы сыйфатында, ә балалар кулланучылар булып чыга. Килешү ахырында «башкаручы тарафыннан үтәлгән эш килешү таләпләрен канәгатьләндерә һәм аның өчен 200 сум күләмендә акча түләнергә тиеш» дигән акт та бар.

Сорау туа: ни өчен Мәгариф һәм фән министрлыгы республика педагоглары көче белән түләүсез имтиханнар оештыра алмый?

**Редакциядән. Хезмәт күрсәтү базарында коммерцияле яңа юнәлеш барлыкка килде, күрәмсең. Азнакай авторы җибәргән түләүле хезмәтләр күрсәтү килешүендә язылганча, «Центр» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте хәзер фән буенча тест оештыру һәм үткәрү, аның нәтиҗәләрен заказчыга (әти-әниләргә) һәм кулланучыга (укучыга) җиткерү дигән хезмәт күрсәтә. Ә нәрсә, начар бизнес түгел. Кызык, Республиканың Мәгариф һәм фән министрлыгында бу хакта ни уйлыйлар икән?**

**Хәким ГЫЙЛӘҖЕВ, ТРның «Мәгарифтәге казанышлары өчен» билгесе иясе. Азнакай, Татарстан Республикасы. («Учительская газета», Мәскәү, 26.04.2011 ел, 8 бит.)**

# Лаеклы тормыш — халыкның хокукы!

## Чистай районында авыл хезмәтчәннәренең беренче протест митингы узды



9 майда Чистайдагы Выселки авылында, бар илебездәге кебек үк, фашистлар Германиясен Җиңү көнен бәйрәм иттеләр. Авыл халкы үз геройларын, Бөек Ватан сугышында катнашучыларны, толларны, солдат аналарын, тыл хезмәтчәннәрен хөрмәтләү өчен клуб янына җыелды. Авыл җирлеге башлыгы В.В. Малышев авылдашларын күренекле бәйрәм уңаеннан ихлас тәбрикләде, ә мәктәп укучылары, үзешчән артистлар концерт программасы әзерләгәннәр иде.

Бәйрәм митингы тәмамлангач та, җыелган халык таралырга ашыкмады, чөнки аларга поселок депутатлары «Лаеклы тормыш – халыкның хокукы!» дип исемләнгән, санкцияләнгән, КПРФның Татарстан региональ бүлеге Чистай бүлекчәсе тарафыннан оештырылган икенче митинг та булачагын алдан ук искәртеп куйганнар иде. Митинг башланырга әллә ни кадәр вакыт алдан ук авылның үзәк мәйданы ак киемле полицейскийларның күплегеннән «балкып торды». Кемнәрне, нәрсәдән сакларга җыенганнардыр, аңлашылмый. 100дән артык кеше ничәмә-ничә елларга беренче мәртәбә, властьлар ишетергә теләгәнне түгел, ә үзләренең ни уйлаганнарын ачыктан-ачык әйтергә мөмкинлек таптылар!

Бу митингның үзенчәлеге шунда, ул авыл халкының үз инициативасы буенча уздырылды: авыл кешесен – гражданлык ягыннан бик үк актив булмаган халыкны, кеше һәм гражданин буларак, дискриминацияләүнең дәвам итүе көчле протестка сәбәп булды. Чистайның үзендә коммунистлар митингларны шактый еш уздырып торалар (мунча ябылу, ТКХ тарифларының артуы, балык тотуны тыюлау итү уңаеннан һ.б.лар), ә менә бусы Татарстан Республикасында, Чистай муниципаль районында хакимлек итүче партия җитәкчелегенең эшчәнлегеннән канәгать булмаган авыл халкының шулай оешып чыгуы беренче тапкыр иде.

2003 елда Россиядә шундый митинг Свердловск өлкәсендә булып узды, шуннан соң Россиядә дә, Татарстанда да күзәтелгәне булмады. Чистайдагы Выселкидан шәһәрнең дә, авылның да депутат-коммунистлары «гаепләнә» табып, тәнкыйть утында кыздыру өчен түгел (андый заманнар артта калды инде), ә берничә дистә еллар дәвамында хәл итеlә алмаган мәсьәләләр турында уртага салып сөйләшергә, конкрет эш планы билгеләргә, район җитәкчелеген авылга йөз белән борылырга һәм бирган вәгъдәләрен үтәргә мәҗбүр итү юларын билгеләргә дип җыелдылар.

Еллар узды, дистә еллар... Бөек Ватан сугышында җиңүчеләрнең тормышы ни дәрәҗәдә үзгәрде соң? Алар ничек яши? Балалары, оныклары нинди шартларда гомер кичерә? Безнең авыл халкының тормыш-көнкүрешен Европадагы шартлар белән чагыштырырлыкмы?

Чистай муниципаль районы тарихында беренче тапкыр авыл халкы, берәмберәм түгел, ә бердәм булып, халыктан 10 ел дәвамында республиканың, муниципалитетның төрле инстанцияләренә юлланган язмача һәм телдән мөрәҗәгатьләренә район җитәкчелегенең җинаятьчел салкын каравына протест белдерделәр. Бу инде кешелек һәм гражданлык хокукларының оятсызларча дискриминацияләнүенә каршы халыкның бунтарьларча сәнәк-балта тотып түгел, ә цивилизацияле таләпләр белән чыгуы.

Митингтагыларның кулларында лозунглар: «Лаеклы тормыш – халыкның хокукы!»; «Безне кем ташлады: Россияме? Татарстанмы? Чистай җитәкчелегеме?»; «Бары тик бердәм булганда гына, үз хокукларыбызны яклый алырбыз!»; «Бөек Ватан сугышы солдатының балалары һәм онықлары туңарга мәҗбүр!»; «Авылларга карап, йөрәк елый...»; «Чистайдагы Выселкида кайчан юллар һәм су булыр?»; «Алдаулардан арыдык!»...

Митингта КПРФның Чистай шәһәр комитеты беренче секретаре Ю.Н. Петров, ТР Дәүләт Советы депутаты Х.Г. Миргалимовның ярдәмчесе И.М. Фатыйхов, авыл җирлеге депутатлары С.А. Чернышов, Е.А. Князев, авыл халкы: И.М. Спирин, В.И. Чурбанова, Ю.А. Чернышова, Т.З. Закирова, Л.В. Дрюкова, А.В. Метенжити, В.И. Огаркин, Чистай шәһәр Советы депутаты В.А. Князева чыгыш ясадылар. Барлык чыгышлар да төпле, тирән фикерле булып, авылда яшәүчеләрнең көнел халәтен, кәефен чагылдыралар иде.

Митингка Чистай муниципаль районы җитәкчеләре, партияләр һәм оешмалар вәкилләре чакырылган булса да, аларның берсе дә килмәде. Нигә дип, барып мәшәкатьләнергә әле, берәр җайсыз сүз әйтеп, кешеләр кәефне кырып куйса... Кул астындагыларга әмер биреп, видео-кинога төшертеп алып, гозерле-әрнүле кешеләрнең күзләренә туры карамыйча гына, «теге коммунистларның» тагын ни «майтарганын» уңайлы кабинетта карап утыру күпкә җайлырак, күпкә рәхәтрәк ич. Ә бит «теге коммунистлар» 2010 елның декабрендә үк төрле партия членнары, партиясезләр, җәмәгать оешмалары вәкилләреннән торган бердәм фронт оештырырга, аларның уртак тырышлыгын җыелган проблемаларны хәл итүгә юнәлтергә, уртак эш башкарырга дигән башлангыч белән чыкканнар иде. Башлыкка, «әлеккеге зирәк» остазларын тыңларга түгел, ә оппозицияне файдаланырга тәкъдим итеlгән иде. Коммунистларның ул тәкъдим-ниятеннән көлделәр генә: «Кемгә каршы көрәшәсез?», янәсе. Ә хәзер шуңа охшаш тәкъдим Путин теленнән чыккач, ирония белән сарказмга урын калмады. Үтәргә кирәк – сайлауларга ерак калмый.

Митингта Чистайдагы Выселки авылыннан барлыгы 120 кеше катнашты.

**В.А. КНЯЗЕВА, Чистай шәһәр Советы депутаты.**

# Авылларда коммунистлар бармы?

Республика буенча йөргәндә бу сорауны еш бирәләр. Барын бар, әмма алар аз. Аның үз сәбәпләре бар. Беренче төп сәбәп – авылның хәзерге хәле анда бернинди партиягә дә, шул исәптән идарә итүче партия булган «Бердәм Россия»нең үзенә дә сыенырга мөмкинлек бирми. Авылдагы рухи төшенкелек, эшсезлек, мохтаҗлык андагы халыкның дәүләткә ышанычын бөтенләй бетергән. Андагы халыкка политик партияләр турындагы федераль законны тормышка ашыру беренче дәрәҗәдәге зарурлык түгел. Чөнки законнарның яшәү белән үлем мәсьәләсен хәл итә торганнары да эшләми. Колхоз-совхозлар бетте, мәктәпләр ябылу дәвам итә, авыл больницалары күптән ябылды инде. Ә сайлауларга барган авыл халкының 99%ы үзләрен газапка салган идарә итүче партиягә тавыш биргән булып чыга. Моңа, әлбәттә, беркем дә ышанмый. Ялганга каршы коммунистлар гына көрәшергә тиешмени? Ни өчен ялган сайлаулар безнең җитәкчеләрне канәгатьләндерә генә түгел, алар аны оештырып йөриләр? 13 май көнне мин Татарстан прокуроры Кафил Фахразиевич Әмировның үзенә сайлауларда закон бозучыларны җавапка тартуны сорап гариза бирдем.

Мәетне укол ясап терелтеп булмаган шикелле, авылны партия оештырып кына аякка бастырырга соңардык инде. Авылга дәүләт йөз белән борылырга тиеш!

Шулай да авылның киләчәге өчен чын күңелдән борчылган кешеләргә мөрәҗәгать итеп әйтәсем килә, әйдәгез, бергәләп, берләшеп үз хокукларыбыз өчен көрәшик. Иң беренче итеп быел декабрьдә Госдумага булачак сайлауларда алдашуларга юл куймас өчен КПРФ партиясе белән хезмәттәшлек итүгә алыныйк. Сайлау комиссиясе членнары, күзәтүчеләр, агитаторлар булып эшләргә теләсәгез, районнардагы партия оешмасы секретарьлары белән элемтәгә керегез. Шуның өчен сезгә КПРФның җирле бүлекләре җитәкчеләренең исемлеген тәкъдим итәбез. Дерес, сезне куркытырлар, эштән куу белән янаучы җитәкчеләр дә табылыр, балаларыгыз, семья членнарыгыз аша да басым ясарлар. Бирешмәскә кирәк! Илебезне һәм халкыбызны саклап калу хакына көрәшнең башкача җиңелрәк юлы юк.

**Хәким ГЫЙЛӘҖЕВ, «Татарстан коммунисты» газетасы баш редакторы.**

## КПРФның Татарстандагы җирле бүлекләре

| Районнар, шәһәрләр | Партия комитеты секретаре | Телефон |
|---|---|---|
| **Казан** | Федоров Владимир Васильевич | 843-238-00-38 |
| Авиатөзелеш (Казан) | Вәлиев Альфред Рәкибович | 9172686666 |
| Вахитов (Казан) | Андреев Евгений Юрьевич | 9178961186 |
| Киров (Казан) | Вәлиуллин Илшат Ришатович | 9600454325 |
| Мәскәү (Казан) | Сәмигуллин Мансур Сәгидуллович | 9179213315 |
| Яңа Савин (Казан) | Сәрвәретдинов Айдар Саматович | 9272446643 |
| Идел буе (Казан) | Буторин Антон Валерьевич | 9274452000 |
| Совет (Казан) | Тарасов Вячеслав Тарасович | 8432986915 |
| **Чаллы** | Гурьева Татьяна Ивановна | 9172921357 |
| Автозавод (Чаллы) | Фазлыева Неонила Сергеевна | 855-254-96-91 |
| Комсомол (Чаллы) | Кормилицин Алексей Егорович | 9179011136 |
| Үзәк (Чаллы) | Потанкин Андрей Петрович | 855-252-82-87 |
| Алексеевский | Галкин Петр Семенович | 843-412-40-74 |
| Әлки | Шәйхетдинов Илнар Әсхәтович | 9274036101 |
| Арча | Шакиров Фирдинад Мәгъсумович | 843-663-21-29 |
| Әтнә | Шиһапов Марс Габделхакович | 843-692-11-89 |
| Буа | Садриев Илдар Исмәгыйлевич | 9033145662 |
| Биектау | Хисамов Госман Сафович | 9178746788 |
| Зеленодольск | Мурахов Вячеслав Николаевич | 9061157083 |
| Кайбыч | Нуруллин Ришат Габдуллович | 9375202610 |
| Кама Тамагы | Вәлиев Исфан Ильясович | 843-77 2-12-58 |
| Кукмара | Иванов Владимир Арсентьевич | 9274417180 |
| Лаеш | Фәйзуллин Наил Гарифович | 9063241643 |
| Нурлат | Яруллин Ришат Галимханович | 9274364174 |
| Питрәч | Артемьев Георгий Григорьевич | 9178548682 |
| Спасс | Владимиров Виктор Иванович | 9600304941 |
| Тәтеш | Калинин Александр Николаевич | 843-732-81-73 |
| Чистай | Петров Юрий Николаевич | 9872963910 |
| Әгерҗе | Ниязов Эрнст Фәхретдинович | 9093086831 |
| Азнакай | Гыйләҗев Хәким Миргалимович | 9600623230 |
| Актаныш | Мансуров Сәгыйть Рахимҗанович | 9600888352 |
| Әлмәт | Кадомцев Виктор Александрович | 9274736032 |
| Баулы | Мөдәрисов Тимербәк Мөдәрисович | 855-695-66-06 |
| Бөгелмә | Котлыбаев Марат Салихович | 9179101107 |
| Алабуга | Гарифуллин Мансур Зәйдуллович | 9625798200 |
| Зәй | Гафиатуллин Әнвәр Ибраһимович | 9178763485 |
| Лениногорск | Никитин Валерий Георгиевич | 9196206099 |
| Мамадыш | Исмәгыйлев Шамил Йосыпович | 9172488164 |
| Менделеев | Ерохин Леонид Сергеевич | 9172382729 |
| Мөслим | Мәрданшин Шәрипҗан Закирҗанович | 9274848827 |
| Түбән Кама | Максимов Николай Николаевич | 9172705975 |
| Сарман | Фәрукшин Хәмзә Газетдинович | 9196235145 |
| Тукай | Минсафин Салихҗан Гаязович | 9053733432 |
| Ютазы | Шмуровец Валентина Федоровна | 9274946888 |

# Язучы Фоат САДРИЕВ бездә кунакта

*Фоат Минлеәхмәт улы Садриев 1941 елның 10 мартында Татарстан АССРның Мөслим районы Олы Чакмак авылында туа. 1972-1981 елларда ул – Мөслимдә чыга торган «Авыл утлары» исемле район газетасының редакторы. Эшеннән аерылмыйча укып, 1965 елда В.И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының филология факультетын тәмамлый. 1981 елдан – Татарстан Язучылар союзы члены. 1981-1982 елларда Мәскәүдә РСФСР Культура министрлыгы каршындагы бер еллык Югары театр курсларында укып кайта. Ф. Садриев – 1962 елдан Коммунистлар партиясе члены.*

*11 мартта язучы, драматург, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Мөслим районының мактаулы гражданы Фоат Садриев 70 яшьлек юбилеен билгеләп үтте. ТР Дәүләт Советы председателе Фәрит Мөхәммәтшин юбиляр адресына Рәхмәт хаты юллады. Анда мондый сүзләр бар:*

*«Татарстан Республикасының мәдәни үсешенә үзегездән зур өлеш керткән өчен Сезгә зур рәхмәтемне белдерәм. Сезнең проза әсәрләрегездә чагылыш тапкан актив иҗат һәм иҗтимагый эшчәнлегегез, бай тормыш тәҗрибәгез укучылар арасында һәм әдәби даирәдә Сезгә карата зур ихтирам уятты. Сезгә киләчәктә дә ныклы сәламәтлек, озак еллар актив тормышта яшәвегезне, Сезгә һәм якыннарыгызга иминлек һәм уңышлар телим».*

*Котлауларга республика коммунистлары һәм газетабызның даими укучылары да кушыла. Язучы Фоат Садриев безнең газетага үзенең публицистик язмасын тәкъдим итте.*



## Эшсезлек ничек тудырылды?

Кешене кеше иткән, һәрчак бурыч тойгысын югары тотарга, мин башкаларга, илемә файда китерәм, дигән тойгы белән горурлану чыганагы булган хезмәт мәйданнарын кыскарту, юк итү планлы рәвештә тормышка ашырылды. Моның өчен иң элек, булган һәм булмаган гаепләр тагып, колхоз-совхозлар юк ителде. Приватизация исеме астында ил байлыгын үз кулларына эләктереп тәҗрибә туплаган Чубайслар соңгы кагылгысыз байлыгыбызга – Ватаныбыз басып торган җиргә кул суздылар. Коллектив хуҗалыкларны җимерү шуның беренче этабы булды. Гөрләп эшләп торган техника юк кына хакка аерым кешеләр кулына күчеп бара. Фермаларда тупланган мал-туар да шундый ук аяныч язмышка дучар ителде. Әйтерсең лә авылны кылыч белән турап ташладылар. Шушыннан соң хөкүмәт оҗмах вәгъдә итте. КФХ, ОАО, ООО кебек алдавыч исемнәр табып, нилләрдер оештырдылар. Тик берсенең дә куандырганы юк. Чөнки эшсезлектән соң авыл өстендә нормаль кеше күтәрә алмастай икенче Газраил чалгысы уйный башлады. Бусы – тир түгеп эшләгән кешегә хезмәт хакы түләмәү. Акчасыз яшәп булмаганлыгын исбатлап торырга кирәкмә. Шушы юл белән авылны хәлсезләндереп, сыгылып төшәргә, егылып җан бирергә мәҗбүр иттеләр. Бүген авыл булган җирләрен сөреп, эшкәртеп бетерә алмый: ягулык юк, запчасть юк. Чәчүен тиешенчә чәчә алмый: ашлама, агу-химикатлар алырга акча юк. Печән өсте, терлек азыгы хәзерләү чоры керсә, урып-җыю башланса, кара кайгы: ягулыкка, запчастька, техникага бәяләр сикерә, кытлык башлана. Элек колхоз-совхозлар исән чакта, коллектив милек булганлыктан, дәүләт кайгырта иде. Хәзер бездә шәхси милек, социализм тәртипләрен онытыгыз, имеш. Көнбатышта яшәп ятучы капиталистлар авыл хуҗалыгына 40 процентка кадәр дотация биргәндә, безнең Россия хөкүмәтенең 1 процент кына тамызуын ничек аңларга соң?! Игенчелекнең һәм терлекчелекнең үсешен төрле чаралар белән буу нәтиҗәсендә илдә ашлык җитештерүнең, мал-туарның катастрофик кимүе, ел саен 2000 авылның юкка чыгуы кемгә файдалы? Бу фаҗигале статистик мәгълүматларны күрмәү өчен тома сукыр, ишетмәү өчен чукрак булырга, туктату чарасын күрмәү өчен акылга камил булмау кирәк.

Соңгы 10-15 елда авылның тышкы кыяфәте үзгәрүгә хәйран калмалы. Әйтерсең лә үтмәс рәнҗү эләккән кеше үзенең соңгы көннәрен көтә. Йорт-курасы ташланган ихаталар авылга кызганыч мескенлек биреп тора. Урамнар куркыныч. 30-40 ел элек төзелгән шактый мәдәният йортлары, мәктәпләр, кибетләр, хакимият биналары, медпунктлар, мастерскойлар, терлекчелек тораклары авария хәлендә. Әгәр авылны яшәтү өчен акча бирелми икән, мәсьәлә ачык: аны кемнәрдер үз кесәсенә сала. Алларына килгән икмәккә, ит-майга, катык-сөткә үрелгәндә, авылның бушка эшләүче уллары-кызларын искә төшерүче түрәләр бар микән ул? Ә бит без үзебезне цивилизацияле кешеләр дип атыйбыз, һәр нәрсә турында зурдан кубып, әүлия булып сөйлибез, үзебезне иң гадел, иң югары әхлакка ия камил затлар итеп күрсәтергә яратабыз. Ә авыл кешеләрен күрәләтә изүне, талауны, аларны хезмәттән, укудан, ялдан мәхрүм итүне цивилизацияле кешеләр гамәле дип атап буламы соң?! Барлык язылган һәм язылмаган кануннар буенча иң рәхәт яшәүче, иң бай кеше – авыл кешесе булырга тиеш. Чөнки ул сәгатьләп эшләми. Аның өчен кимендә ике смена: берсе – җәмгыять өчен, икенчесе – шәхси хуҗалыгында. Авыл башкача яши алмый. Димәк, яшәү шартлары авыр, салган хезмәте күләменең зурлыгы өстенә, җәмгыять өчен дә беренчел әһәмияткә ия булганлыктан, авыл халкы иң өстен хокуклы катлау булырга тиеш. Әмма чынбарлыкта нәкъ киресе хөкем сөрә. Моннан бер генә нәтиҗә ясап була: гаделсезлеккә юл куйган дәүләт беренче чиратта үзе гаделсез. Балаларына карата күрәләтә гаделсезлек кылган, аларны рәнҗеткән ата-ана балаларының үзен яратуына исәп тота алмый. Моның азагы фаҗига белән бетә.

Ничәмә-ничә еллар халык Г. Камалның «Банкрот» пьесасын радиодан тыңлап, телевизордан карап, тәгәри-тәгәри көлде. Әллә инде шуның каргышы төште, халык авылы-авылы белән банкротлыкка чыга башлады. Кешеләре көнә-төнә эшләп торган, эшләгәне өчен акча да алмаган авыл хуҗалыгы предприятиесе ничек банкротлыкка чыгарга мөмкин? Моны үсеш этабы итеп аңлата башлагач, халык та бераз тынычланган кебек булган иде. Колхоз-совхозларның 75-76 ел буе җыйган байлыгын читтән килгән кемнәргәдер биреп озатырга тотынгач, «прихватизация»нең ни белән беткәнен күргән халык күз алдындагы законсызлыкка ризасызлык белдерде. Әмма... берни дә үзгәрмәде, талау бүген дә дәвам итә. Хәзер бер нәрсә бәхәссез: бу эш югарыдагылар өчен кирәк. Алар моңа алдан ук, төптән уйлап әзерләнгәннәр. Барлык процесслар законлы, юридик нигездә башкарыла. Банкротлыкка чыгару эше белән шөгыльләнүчеләр республика Арбитраж суды тарафыннан билгеләп куелган. Тик ул куелучылар арасында, көндез чыра яндырып эзләсәң дә, шушы җирлек, шушы район кешесен күрмәссең. Халык милкен сату белән эш итүчеләр (алар управляющийлар дип йөртелә) йә Казанда, йә башка җирләрдә утыра. Аларның нишләгәнен милек хуҗалары булган халык белми дә, күрми дә. Ул вәкилләрнең һәрберсенә фәлән хуҗалыкны банкротлыкка чыгару миссиясе йөкләнгән. Шушы миссияне үтәп чыкканчы, алар әлеге хуҗалыкларның һәркайсыннан бик солидный гына суммада хезмәт хакы каера икән. Банкротлыкка чыгару механизмына (законына) гына игътибар итегез: хуҗалыкның банкка яисә кредит бирүче бүтән оешмага кимендә 100 мең сум бурычы булып, аны 3 ай эчендә түләмәсә, аны банкротлыкка чыгарырга мөмкин. Әйтик, мартта алган бурычыңны июньдә ничек түләмәк кирәк?! Әле бит игеннәр күтәрелеп кенә килә, маллар көтүгә чыгып кына маташа. Димәк, теләсә кайсы авыл хуҗалыгы предприятиесен әлеге хәйләкәр һәм тозсыз закон нигезендә ансат кына банкротлыкка тәгәрәтергә мөмкин. 3 ай эчендә игенне чәчеп, үстереп, урып, дәүләткә тапшырып акчасын алып булмаганлыгын ул законны кабул итүчеләр белгән ич. Димәк, алар законлы рәвештә талауны ил күләмендә җәелдерүне күздә тотканнар. Акылга камил кеше симертүдәге терлекне дә, шүредән өреп кабарткандай, 3 ай эчендә симертеп булмаганын бик яхшы аңлый, минемчә. Бусына төшендек.

Хәзер милекне сатуга күчик. Бусы әзен ЦРУ да төшенә алмаслык яшерен юл белән башкарыла. Бервакыт аяз көнне яшен суккандай, халык аһ итә, бәргәләнә: хуҗалыкның техникасын, мал-туарын юк кына хакка аткара башлаганнар! Тик шушы җирдә ата-бабалары тир түккән, гомуми көч белән дистә еллар буе уртак байлыкны тудырган кешеләр генә читтә кала.

Бөек Ватан сугышы вакытында өч-дүрт килограмм ашлык урлаган өчен төрмәгә утыртканнар. Бик зур гаделсезлек, коточкыч рәхимсезлек булган бу. Ләкин ул чакта канлы сугыш барган. Илнең исән калу-калмавы үлчәүгә куелган, һәр пуля, һәр башак дошманны җиңү өчен кирәк булган. Әле сугыштан соң, 60нчы елларга кадәр халык милке каты сакланды. Колхозның гомуми җыелышларында хәттә ыңгырчак, дилбегә, аркалык югалткан кешеләрдән аларны түләттерәләр иде. Хәзер миллионлап урлыйлар, тик алар җәмгыятьтә зур эшлеклеләр, бизнесменнар, җитәкчеләр булып йөриләр. Әгәр ул каракларның байлыклары тартып алынса, авыл халкы да, эшчеләр, медиклар, укытучылар, культура әһелләре акчага тилмермәс иде. Яңа эш урыннары булдырылып, йортлар төзелеп, авыллар чәчәк атар иде. Халык байлыгын законсыз эләктерүчеләр фашист армадасыннан көчлерәк булып чыкты. Ата-бабаларыбызның гомерләре һәм каннары белән саклап калган җирләребез дә аяк астыбыздан китеп бара. 6-7 гектар пай җире өчен 2 центнер ашлык алучы кешене җир хуҗасы дип атап буламы соң? Ә бит районнар буенча уртача уңыш 30-40 центнер! Күпме ашлык тияргә тиешлеген кара акыл белән булса да хисаплап карасак, чәчләрең үрә тормалы! Акыртып талау дип атала бу! Югыйсә ничек матур сөйли безнең җитәкчеләр. Матурын матур, тик ихлас түгел. Ихлас булып тоелсын өчен сүз араларына «Алла» сүзен дә кыстыргалап, тагын бер гөнаһка баталар. Хәер, Аллага ышанган кеше бу кадәр коточкыч талауларга җөрьәт итәр идемени?! Ахырда бер нәтиҗәгә киләсең: безнең җәмгыятьтә Алладан да, Президенттан да, законнардан да курыкмыйча, алтынга төренгән катлау барлыкка килде бугай. Ул катлауга керүче затлар һәркайсы пирамиданың үз баскычында Алла булып утыра. Аларның байлык туплаудан тыш бер генә шөгыле бар: матур сүзләр сөйләү, мактану һәм мактату. Аларда халык кайгысы сүздә генә. Әгәр гамәлдә булса, чит ил ризыгы ашап, чит илдә ял итеп, чит илдә сәламәтлекләрен ныгытып, чит илдә виллалар алып, балаларын чит илдә укытып гомер кичермәсләр иде. Менә сиңа әхлак, менә сиңа үз халкыңа мөнәсәбәт. Халык барысын да күреп тора, аңлый, әмма чарасыз...

«Татарстан коммунисты» («Коммунист Татарстана»)
Баш редактор – Хәким ГЫЙЛӘҖЕВ
Техник редактор – Дмитрий ДЕНИСОВ
Телефон: 9600623230, факс: (85592) 7-56-46
Электрон адрес: ursai55@rambler.ru,
www.kprf.ru («Коммунисты и российское общество»)

Газетаның учредителе: КПРФның Татарстан региональ бүлеге.
Учредитель һәм редакциянең адресы: 420012, а/я 3, Казан шәһәре,
Маяковский урамы, 18/39, офис 10. Тел./факс: (843) 236-28-05, 238-00-38
Газета Элемтә, информацион технологияләр һәм күмәк коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республика идарәсендә
ПИ №ТУ 16-00314 таныклыгы белән 19.02.2010 елда теркәлде.
Басарга кул кую вакыты: график буенча – 25.05.2011 ел, 10.00, кул куелды – 10.00.

«Бөгелмә типографиясе» ААҖ
423230, РТ, Бөгелмә шәһәре,
Карл Маркс урамы, 32
Телефон: (85594) 4-85-49
Заказ 44. Тираж 15000.
Бәясе ирекле.